| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МАЛОЦИЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ<br>ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Тел.: (84375) 39-3-35; 39-4-72, факс: (84375) 39-3-35, e-mail: MceI.Drz@tatar.ru,


РЕШЕНИЕ *с.Малая Цильна* КАРАР

2024 елның 24 мае № 39/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында "Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советының 25.05.2023 № 30/3 карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (27.07.2023 № 31/1, 21.08.2023 № 32/2, 18.12.2023 № 36/2 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

8 статьяның 1 пункты түбәндәге эчтәлектәге 12 пункт белән тулыландырылсын:

«12) яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба анкетада булган мәгълүматлар).»;

11 статьяның 1 пунктының 8 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелсен:

"8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;»;

13 статьяның 3 пунктының 2 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелсен:

«2) 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;»;

20 нче маддәнең 2 нче пунктында:

а) 11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 11_1 пунктчасы белән тулыландырырга:

11_1) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга билгеләнгән форманы кертүне рәсмиләштерү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, үз көченә керә.

Глава Малоцильнинского сельского поселения: Г.Ш.Халитов